| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 март г.Казань № 345

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе коллегиясе составын раслау турында» 2008 ел, 27 март, 192 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе коллегиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе коллегиясе составын раслау турында» 2008 ел, 27 март, 192 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 31 декабрь, 954 нче; 2009 ел, 8 октябрь, 688 нче; 2011 ел, 26 апрель, 337 нче; 2012 ел, 7 август, 671 нче; 2014 ел, 1 февраль, 55 нче; 2014 ел, 30 декабрь, 1070 нче; 2015 ел, 21 октябрь, 790 нчы; 2015 ел, 30 декабрь, 1023 нче; 2016 ел, 13 май, 313 нче; 2018 ел, 23 май, 393 нче; 2019 ел, 15 апрель, 288 нче; 2019 ел, 6 декабрь, 1118 нче; 2020 ел, 14 декабрь, 1132 нче; 2022 ел, 14 февраль, 127 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе коллегиясе составын һәм аның әгъзалары санын 14 кеше итеп расларга.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе коллегиясе составында:

Эдуард Яфәс улы Вафинның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе»;

Чулпан Илдус кызы Илдархsecurityнованың вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге» башлыгы».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин